وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№15 (132). 13 апрель 2012 / 22-җөмәдел-әүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Шәкертләрне фикерләргә өйрәтик! ▷2◁



Мәрҗани мәчете: тарих һәм хәзерге заман ▷2◁



"Касыйдә" дип нәрсәне атаганнар? ▷3◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

### ГЕР КҮТӘРҮ БУЕНЧА ЯРЫШЛАР ҮТТЕ

8 апрель көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте мөселман яшьләре арасында гер күтәрү буенча шәһәр ярышлары үткәрде. Әлеге чарада Мәрҗани, Солтан, Хөзәйфә, Борнай, Ал, Әниләр, Шамил, Өметлеләр, Гадел, Фәрхәт, Рамазан мәчетләре, "Мөхәммәдия" һәм Ислам дине кабул итүнең 1000 исемендәге мәдрәсә шәкертләре катнашты. I урынны "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең III курс шәкерте Юмакулов Әнвәр алды, II урын - Ислам дине кабул итүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсәнең III курс шәкерте Сиражев Рәмискә, III урын "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең I курс шәкерте Әдилов Юныска бирелде. Җиңүчеләргә дипломнар, медальләр һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

### КАЗЫЙЛАР ШУРАСЫ УТЫРЫШЫ БУЛДЫ

9 апрельдә мөфтият бинасында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Казыйлар шурасы утырышы узды. Утырышта Кама алды төбәге казыятенең эшчәнлегенә күзәтү ясалды. Әлеге казыяткә Түбән Кама, Тукай, Алабуга районнары һәм Яр Чаллы шәһәре мөхтәсибәтләре карый. Утырыш барышында әлеге район мөхтәсибәтләренең эшчәнлеге буенча фикер алышу булды һәм алга таба үсеш юллары билгеләнде.

### "ГОСМАНИЯ"ЛЕЛӘР МУСА БИГИЕВНЫ ЗУРЛАЯЧАК

21 апрель көнне Казан шәһәренең Авиатөзелеш районында урнашкан (Северный посёлыгы, Муса Бигиев урамы / 2 нче Армавирский, 38) "Госмания" мәктәбендә тарихыбызны барлау максатыннан, Муса Бигиевка багышланган кичә үткәреләчәк. Мәктәп укытучылары һәм укучылары тарафыннан оештырылган әлеге чара шимбә көндезге сәгать икедә (14.00) башлана.

### БАУЛЫ ИМАМНАРЫ "САКЛАУЧЫ" СЫНЫНА МӨНӘСӘБӘТ БЕЛДЕРДЕ

Баулы мөхтәсибәтенең Гали мәчетендә узган чираттагы утырышта Болгар тарихи-мәдәни ядкарьлегенә кагылышлы мәсьәләләр дә читтә калмады. Баулы мөхтәсибәте имамнарның Даши Намдаковның "Саклаучы (Хранительница)" сынын Болгар җирлегенә куюга каршы булуларын, "Татар тарихын кайтаруның" бу акты татар-мөселман өммәтенең таркалуына китерәчәк", - дигән шикләрен җиткерде.

Утырышта район имам-мөхтәсибе Исмәгыйль хәзрәт Биккинин март аенда үткәрелгән чараларга күзәтү ясаган, имамнарны мөфти Илдус хәзрәт Фәизнең боерыклары белән таныштырган. Шулай ук апрель аенда үткәреләчәк чараларның тәртибе тәкъдим ителгән, мәчетләр әйләнәсендә үткәреләчәк язгы өмәләр турында фикер алышынган.

### ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!

1 апрельдән алып 28 июньгә кадәр 2012 елның II яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылырга мөмкин. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.

Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды

# Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

**Мине Татарстан Республикасы мөфтие итеп сайлап куюга инде бер ел узып та китте. Бу кыска вакыт эчендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте 2011 елның язында планлаштырылган күп кенә программаларны тормышка ашырды. Алда тагын да зуррак эшләр тора. Бүген без бик әһәмиятле мәсьәләләрне чишү өстендә эшлибез: безнең җирлек өчен традицион булган хәнәфи мәзһәбен пропагандалау, экстремизмны булдырмау, имамнарның дәрәҗәсен күтәрү, мөселманнарның хокукларын яклау һәм югары квалификацияле кадрларны әзерләү өчен барлык шартларны тудыру.**

XX йөзнең туксанынчы елларында яулап алынган азатлык дин иреге, меңнән артык мәчет төзелү, дини белем бирүче югары уку йортлары ачылу кебек җәмгыятьтәге уңай үзгәрешләр белән беррәттән, тискәре үзгәрешләрне дә алып килде. Илебезгә чит илләрдән миссионерлар килеп, җирле милли гореф-гадәтләрне һәм дини йолаларны юкка чыгарырга тырышып, үз карашларын тарата башлады.

Моның нәтиҗәсе буларак, республикабызда үз максатларына ирешү юлында кеше үтерергә әзер радикаль мөселман секталары барлыкка килде. Нурлат районындагы террорчыларны юкка чыгару һәм Биектау районындагы җәнҗал минем сүзләремә ачык дәлил булып тора.

Шулай ук быелның апрель ае башында Кол Шәриф мәчетендә булып үткән вакыйгалар турында да әйтеп үтәсем килә. Имам кую кебек гадәти эштән чын спектакль ясадылар. Һәм бу спектакльдә баш рольләрне ваһһабчылар, "Хизбут-тәхрир әл-Ислами", оешкан җинаятьчел төркем вәкилләре һәм милли сепаратчылар башкарды. Барысы да безнең җирлек өчен традицион булган хәнәфи мәзһәбенә каршы берләште. Күрәсең, гарәп илләрендә булып үткән инкыйлаблар эзсез калмаган һәм Россиядә дә үз тарафдарларын тапкан.

Республикабыз өммәтендәге хәлләрне үзгәртү өчен бу, билгеле, бик аз вакыт булуын мин аңлыйм. Моның өчен тагын да күбрәк эшләргә, зур көч куярга туры киләчәк. Меңнән артык имам миңа терәк булып тора. Шуңа да без Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен һәм республикабыз тынычлыгы өчен, балаларыбызның тыныч тормышта яшәве, үсүләре һәм укулары өчен эшлибез.

Әгәр дә узган ел вакыйгаларын искә төшерсәк, аларның барысын да санап бетерү мөмкин булмас. Шуңа күрә иң әһәмиятлеләренә генә тукталып үтәм.

Беренчедән, ТР мөселманнары Диния нәзарәте Уставы, мөхтәсибәт һәм мәхәллә Уставлары Россия Федерациясе законнарына туры китерелде. Эш Коръәни-Кәрим, Сөннәт һәм хәнәфи мәзһәбе нигезендә башкарылды. ТР мөселманнары Диния нәзарәте документларындагы үзгәрешләр РФ Юстиция министрлыгында теркәлү узды.

Икенчедән, мәгариф системасында да уңай үзгәрешләр күзәтелә. Сентябрь аенда Имамнарның квалификациясен күтәрү үзәге үз эшен башлап җибәрде, моның файдасын республикабыз районнарындагы имамнар билгеләп үтте дә инде. Укыту программалары бер стандартка - хәнәфи мәзһәбенә туры китерелде, мәчет каршындагы курслар һәм мәдрәсәләр өчен яңа үзгәртелгән программалар булдырылды, җәйге мөселман лагерьлары өчен яңа программа эшләнелде, мәдрәсә укытучыларының I Республика семинары һәм мәчет каршындагы курслар укытучыларының I Республика семинары үткәрелде.

Диния нәзарәте мөселман уку йортларын финанслау өчен үз тарихында беренче тапкыр акча бүлеп бирә алды. Хәзер безнең мәдрәсәләр коммуналь хезмәт өчен түләү хакында баш ватмый, ә мәдрәсә укытучылары хезмәт хаклары ала башлады. Моңа кадәр без республика мөхтәсибләренә һәм казыйларга хезмәт хакы түләүне оештыра алган идек. Иншә Аллаһ, киләчәктә авыл имамнарына да хезмәт хакы түләрбез.

Яхшы хезмәт хакы түләп, без алардан тирән белем бирүләрен һәм югары квалификацияле кадрлар әзерләүләрен көтәбез. Шуңа күрә үзган атнада барлык мәдрәсәләрдә дә укытучылар өчен аттестация башланды. Башка өлкәләр буенча финанс эшләренә килгәндә, анда да эш бара.

**(Ахыры 4 нче биттә.)**

# ИСЛАМИЯТНЕҢ БӨЕК ГАЗИЗЕ

**“Гадәттән тыш зирәк, тырыш” (Г.Ибраһимов)**


**ОЛЫ** диңгез тамчылардан җыела. Милләтебез тарихы да, нәкъ шулай ук, эре һәм вак берәмлекләрдән, чыганак вә гамилләрдән җыйналып, чын, олы тарихка әйләнә. Бибәһа кыйммәтле беренчел чыганакларны барлау, өйрәнү, аларны гыйльми кулланылышка кертү тарихыбызның кайбер “ак тапларын” бетерергә, өр-яңа сәхифәләрен ачарга мөмкинлек бирә. Алай гына да түгел, үтмештәге олуг галимнәребезнең шәхсиятләрен әтрафлы өйрәнү, хакыйкый күзаллау – чорыбыз тарих гыйлеменә зур хисса-өлеш ул.

Мәшһүр исламият укымышлысы, тулы мәгънәсендә мәгърифәтче, күренекле җәмәгать эшлеклесе Муса Җаруллаһ, 1875 елда, Аурупа Русиясендә, Дон елгасы буена карарланган Ростов шәһәрендә дөньяга килгән. Бабасы Габделкәрим хәзрәтләре Пенза төбәге Чембар өязенең Кикин авылында хәят кичергән. Газиз әткәсе Җаруллаһ – остазы Хәбибулла имамның кызы берлән никахта була. Әйтергә кирәк ки, Сәлимгәрәй мөфти Тәфкили аңарга ахун исеме бирүгә ирешкән. Мәгълүм булсын, Җаруллаһ ахун, 1881 елда 45 яшенә җитәр-җитмәс якты белән бәхилләшкән. Муса унбер яшьләренә кадәр газизә әнкәсе Фатыйма абыстайдан сабак күрмеш, соңра ике ел чамасы Ростовта реаль училищеда укый, агасы Мөхәммәдзаһир берлән Казанның Күл буе мәдрәсәсендә гыйлем тәшкил иткәч – Бохараи шәриф, гүзәл Сәмәркәнд, Истанбул, Каһирә, Һиҗаз, Һиндстан, Бәйрут, Шам тарафларында атаклы галим-голәмәдән тәгълим-тәрбия казана. Аерата Каһирәдә остазы-мөфти Мөхәммәд Габдөһү (1849–1904) белән танышу вә Даруль-Кутубил-Мысриядәге (Мисыр милли китапханәсе) мәшгулиятьләр яшь галим Мусага биниһая көчле тәэсир итә. Ошбу елларда ул үзенең иң тәүге хезмәтләреннән (мәгълүм булсын: Муса Бигиевнең безләргә килеп ирешкән 120 җитди хезмәте бар!) “Тарихуль Куръан вәль Мәсаһиф”не яза.

1904 елда Русиягә әйләнеп кайтып, Муса Җаруллаһ ирекле тыңлаучы буларак, Петербург университетының юридик шөгъбәсе-факультетына укырга керә. Шул да мәгълүм булсын – М.Җ.Бигиев әл-Каһирәдә Чистай каласындагы мәшһүр мөдәррис Закир шәехишанның улы Ибраһим Шәүкәт Кәмал берлән таныша. 1905 елда Муса Җаруллаһ аның кыз кардәше Әсма апага өйләнә, киләчәктә аларның алты кыз, ике ир балалары дөньяга килә. Улларыннан Мөхәммәд Бөек Ватан сугышы елларында Польшада һәлак була, Әхмәд абзый әле дөнья тереклегендә – Алманиянең

Мюнхен каласында хәят кичермәктә. Кызларыннан Мәрьям вә Һинд апалар – мәрхүмәләр, 1946 елдан башлап, Уфада тереклек кичерделәр (Аллаһы Тәгалә алардан разый булсачы). Фатыйма апа исә мәшһүр Шәркыять галиме мәрхүм Габдрахман ага Таһиржановның хатыны – Петербургта яшәмәктә.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*



*Муса Җаруллаһ Бигиев*

# Шәкертләрне фикерләргә өйрәтик!

**Безнең эшкә тарих бәя салыр,**
**Әманәтнең бездә изгесе.**
**Безнең кулда милләт киләчәге –**
**Шәкертләрнең күңел көзгесе.**

***Автор***

Мәдрәсәләребездә гарәп галимнәренең иҗатын, аларның әсәрләрен, фикерләүләрен шәкертләребез белә, әмма, кызганыч, татар галимнәренең тормыш юлын, хезмәтләрен алар белеп бетермиләр.

Чит илләрдә йөргәндә миңа төрекләр белән танышырга туры килде. Сөйләшеп киткәч, алар Муса Бигиев турында бик тә кызыклы мәгълүмат бирде. Өйгә кайткач үзем әлеге шәхес турында шәхси эзләнүләр алып бардым һәм аның турында үзем өчен күп кенә кызыклы яңалыклар ачтым. Чыннан да, татар зыялылары үз чорында иҗтимагый һәм гыйльми-мәдәни тормышта гаять зур роль уйнаулары, дөньяви һәм дини белем белгечләре булулары белән мәдрәсә шәкертләре өчен тәрбияви өлге булып торганнар. Безнең Әлмәт төбәгеннән өч бөек шәхес чыга: дин әһеле Ризаэддин Фәхреддин, язучы Фатих Кәрими, галим Һади Атласи (Әлмәт төбәгендә эшләгән). Шуңа күрә, без Әлмәт мөселман мәдрәсәсендә әлеге шәхесләрне өйрәнүгә аеруча зур игътибар юнәлтәбез. Һ.Атласи үзе дә язып калдыра: "Инсанны чын мәгънәсендә илә инсан иткән гыйлем - ул тарихтыр". Р.Фәхреддиннең дә берничә фикеренә басым ясап узасым килә: "Инсан булмак өчен гыйлем өйрәнмәктә холык кирәктер". Әлеге әдип чит илләрдә укымаган, ул үзлегеннән, мөстәкыйль рәвештә гыйлем туплаган шәхес. Без дә шәкертләребезнең өстәмә белем алуларына зур игътибар юнәлтергә тиешбез.

Татар халкының бөек фикер иясе Р.Фәхреддин: "Һәрбер шәкерт, бигрәк тә мәдрәсәнең шәкертләре, бер-берсе белән гүзәл яшәсеннәр, аларны туганнары кебек хисап итсеннәр, очраган вакытларында шатлык белән каршыласыннар, шатлыкларын һәм кайгыларын уртаклашсыннар", - дип язып калдырган. Мәдрәсәдә бердәмлек, дуслык, туганлык булган очракта гына мәдрәсә, гомумән, шәкертләр бергә яши алалар. Әлмәт мөселман мәдрәсәсе шәкертләре дәресләрдә һәм сыйныфтан тыш чараларда галимнәребезнең бай мирасын гыйлем һәм тәрбия чарасы буларак кулланалар. Сыйныфтан тыш уку дәресләре хисабына Ризаэддин Фәхреддин иҗатын укучыларга тирәнтен өйрәтергә тырышабыз. Әхлакый проблемаларны яктырткан әсәрләрне укыганнан соң, фикер алышу өчен нәсихәтләрдән өзекләр китерәбез, укучыларда кешенең эчке дөньясына кызыксыну уятып, үзара мөнәсәбәтләрнең асыллары турында уйланырга мәҗбүр итәбез. Мин үзем "Идел-Урал төбәгендә мөселман фикере тарихы" һәм "Иске имля" дәресләрен алып барам. Өстәмә сәгатьләр алып, кызлар төркемнәрендә шундый алым кертә башладым: иске татар язулы китапларны укып ("Тәрбияле ана", "Тәрбияле хатын", "Шәкертлек әдәбе"), аларны анализлыйбыз. Күптән түгел генә Р.Фәхреддиннең "Тәрбияле ана" исемле китабын укып чыккач, кызлар бер фикер әйтте: бу китапны без ир-ат язган дип уйламас идек, әгәр дә язучысы Р.Фәхреддин булмаса, диделәр. Бу шәхес мәсьәләгә никадәр психологик якын килгән!



*Мәдрәсә шәкертләре дәрес вакытында.*

Районыбыздагы Кичүчат исемле авылда Р.Фәхреддин музее эшли, аның белән даими элемтәдә яшибез: экскурсияләр оештырабыз, борынгы кулъязмаларны алып укыйбыз. Р.Фәхреддин мәктәп-мәдрәсәләрнең вазифалары турында язып, болай ди: "Балаларны мәдрәсәләргә, мәктәпләргә җибәрүдән максат нидә, беләсезме? Әлбәттә, дөрес вә гүзәл тәрбия алудадыр. Мәктәпнең һәм мәдрәсәнең вазифасы да фәкать гыйлем өйрәтү белән чикләнмәячәген, бәлки эченә җыелган шәкертләрнең күңелләрендә Аллаһны сөю, гүзәл гадәтләр, тырышу, эшлеклелек, туганлык, гаилә, инсафлык, гүзәл холык, гаделлек, батырлык, җанлылык кебек яхшылык орлыкларын тәмам игътибар белән чәчү һәм тәрбияләп үстерүдер. Хозурында саф-саф булып тезелгән шәкертләргә мактаулы холыкларыннан дәрес бирүдән элек, мөгаллим булган кеше үз холкын яхшыртырга һәм үз холкы һәм фигыле белән шәкертләргә күчергеч булырга тиештер. Болай булмаганда, шәкертләргә бирелгән нәсихәтләр файдасыз, укытылган дәресләр дә нәтиҗәсез калыр, чөнки күп вакытта балалар мөгаллимнең сүзенә түгел, бәлки, арт көпчәк ал көпчәккә ияргән кебек, фигыленә ияреләр. Соңыннан ияргән нәрсәләре аларда мәхәббәт булып китәр, шуның өчен гүзәл холык өйрәтү турында балалар мөгаллимнең "Шулай булыгыз!", "Болай булыгыз!" дигән фәрманына түгел, бәлки холкы гүзәл булуына мохтаҗ булырлар".

**Энҗе ХӘСӘНШИНА,**
**Ризаэддин Фәхреддин исемендәге Әлмәт ислам мәдрәсәсе директоры**

# КАМА ТАМАГЫНДА – КОРЪӘН УКУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ

**Кама Тамагы район үзәгендәге яңа төзелеп бетеп килгән мәчеттә Коръән укучылар бәйгесе булып узды.**

Бәйгедә авыллардан һәм бистә халкы арасыннан иллеләп кеше катнашты. Авыл мәчетләре имам-хатыйбларыннан, остабикәләрдән тыш, мәктәп яшендәге балалардан алып 80 яшьтән узган өлкәннәр җыйналып, Коръән уку осталыклары буенча көч сынаштылар.

Бәйгене кече яшьтәге кыз балалар ачты. Алар Олы Кариле авылы остабикәсе Зөлхәбирә абыстай шәкертләре иде. Балаларның күбесе шул авылдан килгән. Ир һәм кыз балалар мөселманча матур, пөхтә итеп киенешеп килгәннәр, сөбханаллаһ. Укуда ашыгу, кабалану сизелми, күрәсең, әзерлеклеләр. Һәркайсы Коръәннән кыска сүрәләр, аятьләр укыды. Ир балалар намаз укый белүләрен дә әйттеләр. Олы Салтык ир балалары (аннан икәү) өйлә намазына азан да әйтте. Болар инде киләчәктә дә күңелләренә яшьтән төшкән иман орлыкларын үстерә барырлар, дигән өмет бар, Иншә Аллаһ.



Остабикәләр, имам-хатыйблар арасыннан да укучылар байтак булды. Аннары остазыбыз Фәридә Рәмиева башлангычы, Мөнирә абыстай үгетләүләре белән оештырылган гәрәпчә укырга өйрәнергә йөрүче мөслимәләр үз осталыкларын күрсәтте. Җиңүчеләр дә, җиңелүчеләр дә билгеләнмәде. Иң мөһиме - катнашу, үзең белгәннәрне тикшерү, дөресләү кирәк. Коръәндә дә бит: "Белмәгәнне өйрән, белгәннәреңне бүтәннәргә өйрәт", - диелгән. Бу хакта мөхтәрәм жюри әгъзалары: хаҗи Мәҗит хәзрәт, имам-мөхтәсиб хаҗи Галимулла хәзрәт тә үзләренең вәгазьчыгышларында басым ясап әйтте.

- Коръән аять-сүрәләрен яттан булсын, карап уку булсын - дөрес итеп укырга өйрәнергә кирәк. Юкса хәрефләрне дөрес укымасаң, әйтик сузасын сузмасаң, бер сүз урынына икенче мәгънә, хата китүе бар. Фәридә ханымнан сабак алучылар бүген бүтәннәрдән дөрес укулары белән аерылып тордылар, - дип рәхмәтен белдерде Мәҗит хәзрәт остабикәгә.

Кереш һәм йомгаклау сүзе белән чыккан Галимулла хәзрәт бәйгеҗыенда катнашучыларга олы рәхмәтен җиткерде. Жюри әгъзаларына да, балаларга, сорауларга актив җавап бирүчеләргә истәлек бүләкләре: гарәп язуы әлифбасыннан алып, догалыклар, уку ярдәмлекләре, Коръән китаплары һ.б. тапшырды.

Бергәләп өйлә намазы укыганнан соң, кунакларга Тернәкләндерү үзәгендә чәй табыны оештырылды.

Йомгаклап, бәйгедә катнашучылар исеменнән район күләмендәге әлеге чараны оештыручы имам-мөхтәсиб Галимулла хәзрәткә; шулай ук безне - әлифне таяк дип белмәүче, хәзер инде, шөкер әйтеп туя алмыйбыз, Коръән ачып укый алырга өйрәтүдә дүрт елдан бирле сабырлык белән көчен дә, вакытын да кызганмаган Фәридә ханымга; быелгы кыштан безгә дөрес укырга ныклы таләп итеп өйрәтүче Нурания ханым Исмәгыйлевага; укулар барышын кызыксынып күзәтеп торган Мәҗит хәзрәткә олы рәхмәтебезне әйтәсе килә.

Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтендә булып, әҗер-саваплары үзләренә кайтса иде, дигән теләктә калабыз.

**Р.ХӘЙРУЛЛИНА**

## Очрашу узды

10 апрель көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәте бинасында мөфтинең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов Индонезия Республикасының РФдәге Гадәттән тыш һәм Вәкаләтле илчесе господин Джаухари Оратмангуна, илчелекнең беренче сәркатибе Лейлал Юниарти, Илчелекнең өченче сәркатибе Юри Алвис белән очрашты.

Индонезия делегациясе вәкилләре белән очрашу барышында республикалар арасында тәҗрибә уртаклашу, Татарстан студентларын Индонезиядә укыту мөмкинлеге турында фикер алышынды.



# Нәни

"Мөслимә курчагым - яраткан уенчыгым". Шундый исем астында Чаллы мөхтәсибәте өченче ел инде 10 яшькә кадәрге кызлар арасында курчак бәйгесе уздыра. Быел ул шәһәрнең 2 нче гимназиясенең актлар залында үтте. Бирегә бу көнне йөзгә якын кыз бала үзләре һәм әни-әбиләре ярдәмендә мөселманча киендергән курчакларын (костюмнарын да үзләре иҗат итеп) жюри хөкеменә тапшырдылар.

Әлбәттә, курчаклар башта теркәлү узды. Аларның һәрберсенә аерым сан бирелде. Ә жюри эшләгән арада (курчакларга төрле номинацияләр буенча бәя бирү берничә сәгатькә сузылды) тамашачыларга - кызларның әби-әниләренә, әтиләренә нәни балалар, курчакларын кулларында тирбәтә-тирбәтә, бишек җырлары җырладылар, бала тәрбияләүгә багышланган сәхнә күренешләрен җанландырдылар. Чаллы шәһәрендәге 2 нче гимназиянең "Әлиф" һәм 29 нчы гимназиянең "Энҗе бөртекләре" командалары үзара ярышты. Алар башта үзләре сәхнәләштергән тематик композицияләрне күрсәттеләр. Аннары курчак киендерү биремен үтәделәр. Командаларның осталыгы, артистлыгы бер чамада иде. Бер баллга гына өстен чыгып "Әлиф" кызлары җиңде.

Сәхнәдә башкаручылар берБер артлы алышына торды. Кунаклар - Түбән Кама шәһәренең 25 нче, 76 нчы, 64 нче балалар бакчалары вәкилләре дә яхшы әзерлек белән килгән иде. Алар шигырьләр сөйләделәр, бишек җырлары, мөнәҗәтләр башкардылар. Паузаларда алып баручы Ләйсән Әхмәтова (ул бәйгене оештыручы да) залны гел җанландырып торды, залдагы балаларга табышмаклар, төрле биремнәр бирде, иң беренче булып дөрес җавапны атаучыларга бүләкләр тапшырыла барды. Ә шәһәрнең мөслимәләр өчен булган "Saudiya" матурлык салоны хуҗасы Зәйнәп ханым Камалова мөсел-

# МӘРҖАНИ МӘЧЕТЕ: ТАРИХҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН

**Мәгълүм булганча, 1552 елда Казан ханлыгы рус хакимияте тарафыннан яулап алына. Татар халкының гасырлар буена тупланган матди һәм мәдәни байлыгының күпчелеге илбасарлар тарафыннан талана, юк ителә. Мәчет-мәдрәсәләр, китапханәләр яндырыла, җимерелә. Татар халкының теле, гореф-гадәте, дине кысыла, төрлечә эзәрлекләнә. Көчләп чукындыру, руслаштыру башлана. Чиркәүләр, монастырьлар төзелә. Халыкка зур салым-налоглар салына. Әмма халкыбыз нинди зур авырлыклар, кыенлыклар күрсә дә, үзенең телен, гореф-гадәтен, динен сакларга тырыша. Рус хакимияте рөхсәт бирмәсә дә, халкыбыз мәчетләр, мәдрәсәләр төзи.**



XVIII йөздә руслаштыру, чукындыру сәясәте тагын да көчәеп китә. Төзелгән мәчет-мәдрәсәләр янәдән җимерелә. Бары 1742-1744 елларда гына да Казан тирәсендәге 536 мәчетнең дүрт йөз унсигезе юк ителә.

1762-1796 елларда Россия белән императрица Екатерина II идарә итә. Нәкъ менә ул идарә иткән елларда татар мөселманнарына карата көчләп чукындыру һәм руслаштыру сәясәте бераз йомшартыла. Екатерина II мөселман дөньясына карата рухи басым ясау сәясәте файдасыз һәм, хәтта, зарарлы булуын аңлый. Рәсәйдә яшәүче мөселман халкының милли һәм дини ихтыяҗлары исәпкә алына башлый.

Екатерина II 1766 елда Идел буйлап сәяхәт кыла һәм Казанга да килә. Биредә ул Казан мөселманнары белән очраша, аларның үтенечләрен тыңлый. Екатерина II Петербургка кайткач, Казанның Татар бистәсендә таш мәчет төзергә рөхсәт бирелүе турында Указ чыгара.

1767 елда татар бистәсендә Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, беренче таш мәчет төзелә башлый. Мәчет төзелешенә 62 кеше 5000 сум акча җыя. 1770 елда мәчет төзелеп бетә. Мәчет төзелешен башлап җибәрүчеләрнең берсе һәм аның беренче имамы Әбубәкер бине Ибраһим булган. Әбубәкер хәзрәт үз заманасының танылган дин эшлеклесе һәм Ырынбур Диния нәзарәтенең казые булган. 1793 елда Әбубәкер бине Ибраһимның үлеменнән соң, мәчетнең икенче имамы итеп, күренекле дин галиме Ибраһим Хуҗаш (1825 елда үлгән) сайлана. Ул Кавказдагы Гали әш-Ширвани мәдрәсәсендә гыйлем алган. Тарихи чыганакларда Ибраһим хәзрәт бик тәкъва һәм ихласлы булган дип әйтелә. Ибраһим хәзрәт ислам дине турында берничә китап язып калдырган. 1825-1848 елларда беренче таш мәчеттә имам вазифаларын муллалар - Мостафа Хафизов һәм Сәгыйть Хәмидов башкарган. Алардан соң 1850 елдан башлап 1889 елларга кадәр мәчетнең имамы, мәшһүр дин галиме, тарихчы, фикер иясе, хөрмәтле остаз Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗани булган. Соңыннан мәчет аның исеме белән аталган.

Шиһабетдин Баһаветдин углы 1818 елның 16 гыйнварында хәзерге Әтнә районының Ябынчы авылында рухани гаиләсендә дөньяга килә. Аның бабалары - Мәрҗән авылы кешеләре. Мәрҗани кушаматы шуңа мөнәсәбәттә алына. Шиһабетдиннең әби-бабалары укымышлы, билгеле кешеләр була. Башлангыч гыйлемне Шиһабетдин Ташкичү авылындагы әтисенең мәдрәсәсендә ала. 1838-1849 елларда Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләрендә укып, күп төрле чыганаклар, китаплар белән таныша. 1849 елда туган якларына әйләнеп кайта, Казанның беренче мәчетендә имам булып тора һәм аның янындагы мәдрәсәдә дәресләр бирә. Шиһабетдин хәзрәт мәдрәсәдәге уку-укыту процессын реформалаштыра, программага дөньяви фәннәр кертә. Әлеге мәдрәсә 1871 елда төзелгән була. Бу мәдрәсәдә булачак галимнәр - Габдулла Апанаев, Кәшшаф Тәрҗемәни, Морад Рәмзи укыганнар. Хәзерге вакытта Мәрҗани мәдрәсәсе бинасында Казан ислам көллияте урнашкан.

Озак вакыт беренче таш мәчет Юнысов мәчете дип аталды, чөнки мәчет сәүдәгәр Ибраһим Гобәйдулла улы Юнысов акчасына төзекләндерелгән һәм чыгымнары аның исәбеннән була. 1861 елда Ибраһим Юнысов мәчет тирәли агач койма урынына таш коймa эшләтә, мәчет бинасының төньяк ягына баскыч белән бергә тагын бер бина кушып салдырта. 1863 елда михрабны киңәйтә һәм зурайта. 20 елдан соң, 1885 елда икенче сәүдәгәр Зәйнулла Госманов мәчетнең манарасын үзгәртеп төзетә.

Мәрҗани мәчетенең мөхтәрәм имамы Шиһабетдин хәзрәт - гаять тирән белемнәргә ия булган. Ул, татар, төрки телләреннән тыш, гарәп, фарсы телләрен камил белә. Күп кенә хезмәтләрен гарәпчә яза. Мәрҗанинең утыздан артык хезмәт язуы мәгълүм. Аның хезмәтләренең яртысы диярлек дини фәннәргә (гакыйдә, фикъһе, әхлак, Коръән фәннәре), калганнары тарихка, әдәбиятка һәм телгә багышланган. Шул әсәрләрнең кайберләре хәзерге татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителгән.

1867 елда Ырынбур Диния нәзарәте Шиһабетдин хәзрәтне ахун һәм мөхтәсиб итеп билгели. Ш.Мәрҗани 1889 елның 15 апрелендә 71 яшендә Казанда вафат була. Кабере - Яңа бистә зиратында. Шиһабетдин хәзрәттән соң, мәхәллә башлыгы итеп аның улы Мөхәммәтборһанетдин хәзрәт Мәрҗани сайлана. Мөхәммәтборһанетдин хәзрәт авыру аркасында үзенең мәхәллә эшләрен җиренә җиткереп башкара алмый. 1899 елда халык аңа яшь ахун Сафиулла Габдуллинны ярдәмче итеп сайлый.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# мөслимәләр бишек җыры җырлады







манча яулык бәйләү серләренә төшендерде. Видеороликлар күрсәтелде. Чыгышлардан соң тамашачылар кул чапмадылар, ә күмәк төстә: "Сөбханаллаһ!", "Машаллаһ!" дип сокрануларын белдерделәр.

Бер курчак хуҗасы да дипломсыз һәм бүләксез калмады. Ул нинди дә булса номинациядә җиңүче булды. Ә алар күптөрле иде. Мәсәлән, купшы кием, тыйнак кием, көндәлек кием, кәләш киеме, классик кием, кышкы кием, алтын кул һ.б. номинацияләр. Алар арасыннан иң яхшылары билгеләнде. Бәйгенең җиңүчесе итеп Гайшә Зыятдинова танылды. Икенче урынга Регина Бәдертдинова лаек булды, өченчедә - Камилә Гәрәева.

Аннары бәйгедә катнашучылар һәм тамашачылар ашханәгә чакырылды. Алар биредә тәмле ашлар белән сыйланды. Шуннан соң да әле бәйге тәмамланмады: балалар әниләре ярдәмендә кәгазьдән бишек ясау серләренә төшенде.

Рәсемнәрдә: бәйгедә җиңүче Гайшә Зыятдинова; "Энҗе бөртекләре" кызлары; бәйге күренешләре.

***Хәлил ШӘРИФ,***
***Чаллы мөхтәсибәтенең матбугат үзәге җитәкчесе***

# ИСЛАМИЯТНЕҢ БӨЕК ГАЗИЗЕ

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Мөхтәрәмә Әсма апабыз 1975 елда Уфада вафат булды, кабер шәрифе Уфаның тарихи мөселманнар зиратында.

Кабер ташындагы язулар Г.Таһирҗанов тарафыннан, гарәби хоруфатта башкарылган (Аллаһның рәхим-шәфкатендә була күрсеннәр). Оныклары Акбулатов, Карамышев вә Янгировлар Уфада гомер кичерәләр – җөмһүрият хастаханәсендә табиблык, нефть институтында гыйльми хезмәткәрлек вә төзүче-мөһәндислек (инженер) вазифаларында хезмәт итәләр.

Муса Җаруллаһ ифрат киң карашлы илаһият галиме-теолог вә ислами хокук белгече – фәкыйһюрист булып җитешә. Г.Тукай да аңа шәхес буларак бик югары һәм уңай самими бәя бирә, аның искиткеч тырыш – иҗтиһадлы вә эшлекле, илкөн кәсебендә тынгысыз җан булуына басым ясый. Уку-эзләнү елларында Муса Җаруллаһның ул дәвердәге иҗтимагый тәртипләр берлән килешмәүче даирәләргә якын булганлыгы мәгълүм. Мәсәлән, XX йөз башында ул Петербург эшчеләр оешмасы белән элемтәдә торганлыгы өчен кулга алына һәм Уфага сөрелә, Төркиядә була. Чит мәмләкәтләрне гизеп, Петербургка кайткач, М.Бигиев күренекле галим-җәмәгать эшлеклесе Габдрәшит казый Ибраһимов (1857–1944) белән таныша вә ул нәшер иткән "Өлфәт", "әт-Тилмиз", "Мирьат" кебек басмаларда язышa башлый, сәясәт мәйданына тартыла. Русия мөселманнарының милли-азатлык хәрәкәтенең актив эшлеклеләренең берсенә әйләнә, мөселман нәдвә-съездларын оештыручылардан була, "Иттифак әл-мөслимин" фиркасенең органнарына сайлана, нәширлек белән шөгыльләнә. Ул "Шура", "Вакыт" һәм башка газета-журналлар сәхифәләрендә даими рәвештә бәхәсле мәсьәләләр буенча мәкаләләр бастыра, реферат-трактатлар яза, лекцияләр укый.

Кече күңелле, олы җанлы шәхес була ул – даирәсендәге йә булмаса үзе тирәнтен ихтирам иткән бәндәләрнең эчке дөньясы берлән кызыксына, аларга ярдәм кулы суза. Менә милләтпәрвәрләребездән Садри Максуди (1879–1957) хәятеннән бер мисал. Аңа 31 яшь, әмма гаиләсе юк. Муса Җаруллаһ ошбу хәлгә бик борчыла, берничә тапкыр С.Максудига бу хакта тел тибрәтә. Ниһаять, бөекләребездән Мөхәммәдшакир бине Мөхәммәдсадыйк Рәмиев берлән фикер алышып, аның Камилә атлы кызын ярәшү, иҗабе кабул кылу бәхетенә ирешә: 1910 елның ноябрь аенда Ырынбурда туй үткәзелеп, Садри вә Камилә сәгадәтле гомер кичерәләр.

Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, Муса Җаруллаһ Бигиев Уфага – Каһирәдәге әл-Әзһар университеты буенча сабакташы – бөек исламият йолдызы, мәгърифәтче-педагог Зыяэддин бине Җәмаледдин әл-Кәмали хәзрәтләре (1873–1942) нигез ташларын салган "Мәдрәсәи Галия Диния"гә 1914–1915 елларда өч кәррә килгән. Әүвәл тәшриф боердыгында саулык-сәламәтлек сорашып: "Әссәламегаләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһү, талибәләр", – дип үзе сәлам биреп кергән, соңра алар хозурында фәһемле чыгыш ясаган, нотык тоткан. Уфа халкы олуг галимне күрергә "Галия"гә агылган. М.Җ.Бигиев җәнабләре мәдрәсәгә электр уты кертү өчен кесәсендәге барча 200 тәңкә акчасын биреп, мәдрәсәне яктылык берлән тәэмин иткән. Мәдрәсә идарәсе галим хөрмәтенә зур мәҗлес корган. Хәсән-Гата казый Габәши, мөхәррир-галим Закир Кадыйри, Габдулла Шонаси (Ибраһимов), Хәбиб Зәйни, Тәкый Бәдигый, Җиһанша Габдюшев, Сәедшәриф Җиһаншин вә шәкертләр чыгыш ясаганнар. Соңра Муса Җаруллаһ тирән эчтәлекле нотык тоткан. Ошбу урта буйлы, чандыр бәдәнле, кара сакаллы, үзбәк милли такыясе кигән философ галимне халык йотлыгып тыңлаган. Ул дәресләргә дә йөрештергәләгән – мөдәррисләргә файдалы гыйльми-педагогик киңәшләрен мәслихәт кылган.

**(Дәвамы киләсе санда)**

***Равил ҮТӘБАЙ-КӘРИМИ,***
***Шәркыят вә Исламият галиме***

# МӘРҖАНИ МӘЧЕТЕ: ТАРИХ ҺӘМ ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН

Сафиулла хәзрәт кыска гына вакыт эчендә мәхәлләдә тәртип урнаштыра. 1917 елның 6 июлендә беренче таш мәчетенең соңгы имам-хатыйбы итеп Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең оныгы - Габделхәмид Мөхәммәтборһанетдин улы Мәрҗани сайлана (ул 1886 елда туган).

Мәрҗани мәчете элек-электән Татар бистәсенең генә түгел, Казанның да рухи үзәге булган. Бу мәчет хәтта совет чорында да ябылмаган. Атеизм дәверендә дә Мәрҗани мәчетенең имамнары төпле шәригать белеменә ия булганнар. Алар халыкны армый-талмый хаклык белән таныштырганнар. Шундый хәзрәтләрнең берсе - Габделхәбир хәзрәт Яруллин. Ул 1967 елдан алып 1994 елга кадәр Мәрҗани мәчетенең беренче имам-хатыйбы вазифасын үтәгән.

Бүгенге көндә Мәрҗани мәчетендә Казан мөхтәсибәте урнашкан. Казан шәһәренең имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдинов тырышлыгы һәм дәүләт тарафыннан күрсәтелгән ярдәм белән 2004-2007 елларда Мәрҗани мәчете тулысынча төзекләндерелде. 2007 елга кадәр хатын-кызлар гыйбадәтне мәчетнең аскы катында (подвалында) кылсалар, хәзер исә хатын-кызлар өчен махсус бина төзелде. Шулай ук, конференцияләр, җыелышлар һәм башка төрле чаралар уздыру өчен зур конференц-зал булдырылды. Мәрҗани мәчетендә Тәлгат хәзрәт Таҗетдин, Равил хәзрәт Гайнетдин, Госман хәзрәт Исхакый кебек күренекле дин әһелләре имамлык вазифаларын башкарган.

Мәрҗани мәчетенең хәзерге имамнары Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанинең юлын дәвам итеп, халыкка Аллаһ кануннарын җиткерәләр, ислам әдәбе һәм әхлагы белән таныштыралар.

Рәсемдә: Мәрҗани мәчетенең хәзерге күренеше.

**Нияз хәзрәт САБИРОВ,**
**Казан ислам көллияте директоры урынбасары**

# "Касыйдә" дип нәрсәне атаганнар?




**Сорауга сәнгать фәннәре кандидаты, фольклор белгече Геннадий Макаров җавап бирә:**

*- Язма традицияләргә нигезләнгән бу музыкаль-поэтик жанр татар мәдәниятендә әле дә халык көнкүрешендә сакланып килә. Идел-Урал төбәкләрендә үткәрелгән музыкаль-этнографик экспедицияләр барышында шул ачыкланды: иляһи шигърият белән бәйле күп кенә әсәрләрне халыкта һаман да "касыйдә" дип йөртү күренеше дәвам итә. Һичшиксез, бу атама гади халык мәдәниятенә классик язма шигърият аша кергән. Касыйдә нигезен бәетләр (икеюллыклар) тәшкил иткән. Аларның рифмалары а а, б а, в а... принцибы буенча төзелгән. Касыйдәләр, классик шигырь формасы буларак, гаруз вәзеннәренең берсенә нигезләнеп язылганнар.*

*Урта гасырларның соңгы дәверендәге татар шигъриятендә касыйдә жанры актив кулланылган. Мәсәлән, шагыйрь, җырчы-хафиз, мәкам остазы Вәлид Каргалый (XVIII йөз - 1803) касыйдәләре. Урта гасырларның классик дәверендә касыйдәләр сарай шагыйрьләре тарафыннан ханнарга, җиңүче гаскәр башлыкларына яисә Мөхәммәд пәйгамбәргә, ислам тарихы белән бәйле башка күренекле шәхесләргә багышлап язылганнар.*

*Бүгенге көндәге гади халык көнкүрешендә яшәешен дәвам иткән сәнгатьтә башкаручылар күпчелек очракта теге яисә бу әсәрне кайвакытта "касыйдә" дип әйтәләр, әмма мондый атама сәбәпләрен үзләре аңлата алмыйлар. Алар бу әсәрләрне, элеккедән килгән гадәт буенча, уйлап тормыйча гына "мөнәҗәт" яисә "касыйдә" дип аералар.*

*"Касыйдә" дип, мәсәлән, татар халкында үтә киң таралган "Мәүлидин нәби" иляһи шигырьләр җыентыгы тәшкил иткән китаптагы күп кенә әсәрләр дә аталган. Касыйдәләрнең музыкаль хосусиятләрен, мәсәлән, Солтан Габәши тарафыннан әзерләнгән "Милли моңнар" китабындагы Мөхәммәд пәйгамбәр тормышына, аның исеме белән бәйле кодрәтләрне тасвирлауга багышланган "Касидә-и бөрдә" (сүзләрен мәшһүр гарәп шагыйре Мөхәммәд бине Сәид әл-Бусири (1212-1294) язган), шулай ук "Мөхәммәдия" китабындагы "Касыйдә-и раббания" (авторы Мөхәммәд Чәләби, 1451 елда вафат) мисалларыннан күреп була.*

# Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Ел дәвамында Диния нәзарәтендә булган милек барланды, аларга документлар әзерләнде. Киләчәктә финанс сорауларны һәм имамнарның матди проблемаларын үз өстенә алачак Вакф фонды төзелде. ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршында Мөселман эшкуарлары ассоциациясе оештырылды, алар булышлыгы белән беренче тапкыр Республика ифтары оештырылды. Быел ифтарны тагын да колачлырак итеп уздырырга җыенабыз. Моннан тыш, ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы "Хәләл" комитеты эшләми диючеләрнең сүзләрен кире кагасым килә. Комитет эшли генә түгел, ул зур темплар белән үсүен дәвам иттерә, һәм аның партнёрлары көннән-көн арта бара.

Россиядә беренче басма Коръәннең басылып чыгуына 225 ел тулу уңаеннан Диния нәзарәтенең 2012 елны Коръән елы дип игълан итүен дә әйтеп үтмичә кала алмыйм. Бу уңайдан Казанда һәм республикабызның 45 районында күптөрле чаралар үткәреләчәк. Бүгенге көндә барлык районнарда да диярлек Коръән укучылар конкурслары булып үтте. Якын арада Коръән елына багышланган сайт эшли башлаячак, "түгәрәк өстәл"ләр оештырылачак. Коръәни-Кәримнең Казан басмасы дөнья күрде. Китап 10 мең данә тираж белән басылды.

Бу китапны колонияләрдәге хөкем ителгән мөселманнар да алачак. Диния нәзарәте Татарстанның Җәзаларны үтәтү буенча Федераль хезмәте (УФСИН) белән берлектә төрмә һәм колония китапханәләреннән барлык ваһһаби китапларны алды. Хөкем ителгәннәр өчен махсус китапханәләр оештырылды.

Республикабыз җитәкчеләренең мөселманнар белән үзара мөнәсәбәтләрен аерым ассызыклап үтәсем килә. Моннан тыш, Президент аппаратында яңа структур берәмлек - Татарстан Президентының Дини берләшмәләр белән үзара хезмәттәшлек итү идарәсе төзелде, ул мөселманнар өммәтендә килеп туган агымдагы мәсьәләләрне һәрьяклап хәл итүгә булышлык күрсәтә.

**Үзәкләшкән дини оешма -**
**ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,**
**мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| *Шимбә* | 14.03.12 | 4:11 | 5:41 | 13:02 | 17:33 | 19:49 | 21:19 |
| *Якшәмбе* | 15.04.12 | 4:08 | 5:38 | 13:02 | 17:35 | 19:51 | 21:21 |
| *Дүшәмбе* | 16.04.12 | 4:06 | 5:36 | 13:02 | 17:36 | 19:53 | 21:23 |
| *Сишәмбе* | 17.04.12 | 4:03 | 5:33 | 13:02 | 17:37 | 19:55 | 21:25 |
| *Чәршәмбе* | 18.04.12 | 4:01 | 5:31 | 13:02 | 17:39 | 19:57 | 21:27 |
| *Пәнҗешәмбе* | 19.04.12 | 3:58 | 5:28 | 13:02 | 17:40 | 19:59 | 21:29 |
| *Җомга* | 20.04.12 | 3:56 | 5:26 | 13:02 | 17:41 | 20:01 | 21:31 |
| *Шимбә* | 21.04.12 | 3:53 | 5:23 | 13:02 | 17:43 | 20:03 | 21:33 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №15 (132) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-529.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 12 апрель көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**